РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

«_24_» __июль_________ 2018 ел №_176__

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль район Советы
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән
муниципаль районы Советының
2018 нче елның 6 нчы мартында
141 нче сан астында чыгарылган “Балигъ
булмаганнарның эшләре һәм аларның
хокукларын яклау буенча комиссия турында”
карарга үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасының 2011 нче елның 20 нче маенда чыгарылган № 26-ТРЗ “Татарстан Республикасында балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча чаралар турында”гы Кануны, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 нче ел 24 нче сентябрендә 798 нче сан астында чыгарылган “Татарстан Республикасының 2011 нче ел 20 нче маенда № 26-ТРЗ “Татарстан Республикасында балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча чаралар турында” Балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия турындагы”гы Карары нигезендә, кадрлар үзгәрү сәбәпле, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР БИРӘ**:

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2018 нче елның 6 нчы мартында 141 нче сан астында “Балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия турында” карары белән раслаган комиссия составына үзгәрешләр кертергә:

- Комиссия составыннан Мингазов Ф.Ф. ны чыгарырга;
- Комиссия рәисе урынбасары Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының социаль мәсьәләләр буенча җитәкче урынбасары Долгополова Рәмзия Шакир кызын комиссия рәисе итеп расларга;
- Комиссия әгъзасы, МКУ “Мәгариф бүлеге” башлыгы урынбасары Рәхимҗанова Флера Мансур кызын комиссия рәисенең урынбасары итеп расларга;

- Комиссия составына комиссия әгъзасы, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитет имин булмаган гаиләләрне һәм балигъ булмаганнар арасында хокук бозуны профилактикалау буенча әйдәп баручы белгеч Галиуллина Зелфирә Шәһит кызын кертергә.

Муниципаль район Советы рәисе,
район башлыгы Ф.М. Дәүләтшин